**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5552**
**14.10.2022**

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасы турында

Яр Чаллы шәһәре халкы арасында наркотизацияләүне һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау эшен оештыру максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 23 ноябрендәге 733 номерлы Указы белән расланган 2030 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясе, Татарстан Республикасының «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында балалар сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы Карары, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программа чараларын финанслауны 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 1200 мең сум: 2023 елда – 400 мең сум, 2024 елда – 400 мең сум, 2025 елда – 400 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 14 октябрендәге
5552 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә
халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 23 ноябрендәге 733 номерлы Указы белән расланган 2030 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясе, Татарстан Республикасының «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында балалар сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы Карары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе (алга таба – яшьләр белән эшләү идарәсе) |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе |
| Программаның максаты | Сәламәт яшәү стилен формалаштыруга юнәлдерелгән комплексы чаралар системасын, Яр Чаллы шәһәре халкы арасында психоактив матдәләр куллану һәм таратуга комачаулаучы үз-үзеңне тоту стратегияләрен һәм шәхес ресурсларын булдыру |
| Программаның бурычлары | 1. Халыкта наркотиклар куллануга тискәре караш һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру, халыкның төрле максатчан төркемнәре өчен наркотикларга каршы профилактик чаралар оештыру һәм үткәрү.<br>2. Шәһәр халкы арасында наркоманияне профилактикалауга мәгълүмат-пропаганда ярдәме күрсәтүне тәэмин итү. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2023-2025 еллар |

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | 2025 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 400 | 400 | 400 | 1200 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 400 | 400 | 400 | 1200 |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2025 елга чараларны тормышка ашыру хисабына планлаштырыла:<br>1) яшьләр сәясәте, өстәмә белем бирү, мәдәният һәм спорт учреждениеләрендә шөгыльләнүче 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр санын 1% ка арттыру%;<br>2) профилактик чараларда катнашкан балалар һәм яшьләр санын 0,5 % ка арттыру. | | | | |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаның үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе гамәлгә ашыра | | | | |

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Заманча социаль-икътисадый шартларда наркоманияне профилактикалау халык сәламәтлегенә карата дәүләт социаль сәясәтенең төп юнәлешләренең берсе булып тора.

Наркомания таралуны кисәтүгә юнәлдерелгән күп кенә чараларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә уңай якка үзгәрешләр булды.

2022 елның 1 июленә Яр Чаллы наркология диспансерының рәсми мәгълүматлары буенча «наркотик матдәләргә бәйлелек синдромы» (наркомания) диагнозы белән диспансер исәбендә 1959 кеше (2021 елда – 1937 кеше, 2020 елда – 1917 кеше) тора, 2022 елның 1 июленә профилактик күзәтүдә наркотик матдәләрне күп кулланучы 1765 кеше (2021елда – 1739 кеше, 2020 елда-1696 кеше) тора.

2022 елның 1 июленә наркотикка бәйлеләр структурасы түбәндәгечә:

– 20 яшькә кадәрге затлар өлеше – исәптә торучылар сыныныӊ 0,46% (9 кеше), 2021 елда – 0,26% (5 кеше) тәшкил итә; 20 яшьтән 40 яшькә кадәр – 42,7% (837 кеше), 2021 елда – 44,74% (867 кеше) тәшкил итә, 40-60 яшь һәм аннан зуррак – 56,8% (1113 кеше), 2021 елда – 55% (1065 кеше). Наркомания белән авырып, исәптә торучыларның 62% - эшсез, 38% – эшчеләр һәм хезмәткәрләр (шул исәптән укучылар).

2022 елның 1 июленә беренче тапкыр диспансер исәбенә 32 кеше (2021 елда – 44 кеше, 2020 елда – 40 кеше) куелган.

2022 елның 1 июленә Яр Чаллы шәһәре буенча наркомания таралу күрсәткече – 100 мең кешегә 359,1 тәшкил итте, бу исә уртача республика санына (100 мең кешегә 254,2) карата 1,5 тапкыр артык.

Соңгы өч елда исерек хәлгә 16 меңнән артык (2021 елда – 6533, 2020 елда – 6449 экспертиза, 2019 елда – 3018 экспертиза), шулай ук наркотиклар һәм башка исерткеч матдәләр белән агулануны билгеләүгә (2021 елда – 3200 экспертиза, 2020 елда –

3197 экспертиза, 2019 елда – 3018 экспертиза) экспертиза үткәрелгән, наркотикларга уңай нәтиҗәләр саны 18% тан 20,8% ка кадәр тәшкил итә.

2022 елның 1 июленә, наркотик матдәләрне медицина максатыннан тыш куллану предметына тест үткәреп, укучыларны һәм студентларны профилактик тикшерү буенча мәгълүматлар 1797 кеше тәшкил итте (2021 елда – 6423 кеше, 2020 елда – 5300 кеше). Тестлар 10 төр наркотик матдәгә (морфин, марихуана, амфетамин, метамфетамин, кокаин, метадон, спайслар, мдпв, барбитуратлар, бензодиазепиннар). Ачыкланулар юк.

Шуның белән беррәттән, Яр Чаллы шәһәрендә наркотикларның легаль булмаган базарын интенсив структур үзгәртеп кору бара. Беренчедән, синтетик наркотиклар элекке традицион марихуана, опий һәм героинны кысрыклап чыгара. Икенчедән, наркотиклар сату схемалары үзгәрә. Җинаятьчел эшчәнлеккә белем дәрәҗәсе югары булган һәм, белемнәрен яшерен лабораторияләрдә синтетик наркотиклар җитештерү өчен генә түгел, аларны сатуның законсыз схемаларын оештыру өчен дә кулланучы махсус белемнәре булган затлар җәлеп ителә.

ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат үзәге мәгълүматларына караганда, соңгы 10 елда наркотиклар белән бәйле теркәлгән җинаятьләр саны берничә тапкыр арткан. Әмма, экспертларның күпчелеге фикеренчә, бу цифрлар реаль криминоген хәлне чагылдырмый, чөнки мондый җинаятьләрнең 10-15 проценттан артмаган өлеше генә ачыклана.

Бу – җинаятьчелек мохите оешуның көчәюенә, ә бу өлкәдә җинаятьләр һәм хокук бозуларның массакүләм характер алуына бәйле. Шул ук вакытта полициянең махсус оператив бүлекчәләре хезмәткәрләре җинаятьчел «профессионализм»ның тиз һәм тайпылышсыз үсеше һәм наркотик сатучыларның оешканлыгы, шулай ук балигъ булмаганнарны наркотик матдәләр сатуга җәлеп итүнең куркыныч тенденциясен билгеләп үтә.

Шәһәр яшьләре арасында үткәрелгән сораштырулар нәтиҗәләре буенча түбәндәге закончалык ачыклана: наркотик кулланганда катнашкан яшьләр саны наркотик куллану фактын таныган яшьләр санынннан ике тапкыр күбрәк. Шуңа бәйле рәвештә, яшүсмерләр һәм яшьләрнең наркотик культурасы белән зарарлану куркынычы бик югары булып кала, дип фаразларга мөмкин.

Яшьләр наркомания таралу сәбәпләренә түбәндәгеләрне кертә: тормыштан канәгатьсезлек, социаль иминсезлек – 71,8%, җәмгыятьнең әхлакый деградациясе һәм һәр нәрсәгә ирек куелган булу – 60,2%, гаиләдә үзара аңлашу булмау – 47,8%, хокук саклау органнарының начар эше – 45,6% һәм наркобизнесның йогынтысы, наркотикларны табу мөмкинлеге – 43,6%.

12% тан артык яшьләрнең наркотиклар куллану тәҗрибәсе булган дуслары һәм танышлары бар. Бу, яшьләрнең наркотик исереклеге турында күзаллавын һәм аны башка халәтләрдән (алкоголь, начар хис итү) аера алуын күрсәтә.

Шулай ук яшьләрнең нинди урында наркотиклар сатып алу җиңел булу хакында фикерләре дә әйтелде:

- урамда – 97% респондентҗавап бирде;
- «фатирда» – 86,2%;
- дустында, танышында – 81,2%;
- төнге клубта – 69,8%;
- киоскта – 62,4%;
- Интернет буенча заказ бирү – сораштырылган затларның 57,2%.

Гомумән алганда, сораштыруда катнашучыларның 49,5% ына наркотик матдәләр кулланган, саклаган һәм саткан өчен Россия Федерациясендә закон җаваплылыгы билгеле, 29,1% ына – яхшы билгеле, 15,2% ына – аз билгеле, 4,6% ына – бөтенләй билгеле түгел.

Наркотизацияләү проблемасы наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр булудан гына түгел, ә яшьләрнең, үз сәламәтлекләре турында уйламыйча, рәхәтлек алу өчен, аларны кулланырга әзер булуыннан да гыйбарәт. Шуңа күрә башка юнәлештә дә эшләү

мөһим – наркотикларга ихтыяҗны киметү. Наркотикка бәйлеләрне сәламәтләндерү барлык профилактика субъектларының җайга салынган, килешенгән эше ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

Бүгенге җәмгыятьтә наркотизация һәм наркоҗинаять проблемасы кешелекнең бөтен куркынычсызлык дәрәҗәләренә – конкрет индивидуаль сәламәтлектән алып, бөтен җәмгыять куркынычсызлыгына һәм социаль иминлегенә кагылуына беркемнең дә шиге юк.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында да, аерым алганда, шәһәребездә дә барлыкка килгән ситуацияне анализлау наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше һәм законсыз кулланылышы өлкәсендәге тискәре тенденцияләрнең саклануын күрсәтә, бу исә халык сәламәтлегенә, икътисадка, хокук тәртибенә, шулай ук шәһәр халкы иминлегенә җитди куркыныч тудыра.

Шәһәрдә халыкны наркотизацияләү проблемасы актуаль булып кала һәм үзенә аеруча игътибар таләп итә.

Профилактик эшнең нәтиҗәлелеген арттыру максатында түбәндәгеләрне башкарырга кирәк:

1) ял һәм мәшгульлекне, һөнәри юнәлеш бирү һәм эшкә урнаштыруны, физкультура-спорт чараларын, патриотик тәрбия бирүне оештыру буенча яшүсмерләргә һәм яшьләргә шартлар тудырырга;

2) үз вакытында һәм адреслы социаль-психологик ярдәм күрсәтү буенча социаль әһәмияткә ия социаль проектларга һәм программаларга булышлык итәргә;

3) балаларны һәм яшүсмерләрне наркотизацияләүне профилактикалау мәсьәләләрендә гаиләнең ролен арттырырга;

4) иҗтимагый аңда, барыннан да элек, сәламәт яшәү рәвешен алып баруга юнәлдерелгән кыйммәтләр системасын формалаштырырга;

5) наркотизацияләүне профилактикалау өлкәсендә ведомствоара хезмәттәшлекне, дәүләт органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр белән эшчәнлекне координацияләүне гамәлгә ашырырга.

Әлеге программа кысаларында наркомания таралуга каршы торуның, профилактик эш формаларын һәм методларын камилләштерүнең нәтиҗәле чараларын тормышка ашыруны дәвам итү планлаштырыла.

## 3 бүлек. Тормышка ашыру срокларын күрсәтеп, программаның төп максатлары, бурычлары

Программаны тормышка ашыру өч елга: 2023-2025 елларга исәпләнгән.

Программаның максаты – сәламәт яшәү стилен формалаштыруга юнәлдерелгән комплекслы чаралар системасын, Яр Чаллы шәһәре халкы арасында психоактив матдәләр куллану һәм таратуга комачаулаучы үз-үзеңне тоту стратегияләрен һәм шәхес ресурсларын булдыру.

Программаның бурычлары:

1) халыкта наркотиклар куллануга тискәре караш һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру, халыкның төрле максатчан төркемнәре өчен наркотикларга каршы профилактик чаралар оештыру һәм үткәрү.

2) шәһәр халкы арасында наркоманияне профилактикалауга мәгълүмат-пропаганда ярдәме күрсәтүне тәэмин итү.

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

Программа чаралары наркоманияне комплекслы профилактикалау, шулай ук наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә ведомствоара хезмәттәшлек принциплары һәм төп өлешләре нигезендә билгеләнде.

Программа чаралары системасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләрне үз эченә ала:

1) программаны тормышка ашыруны оештыру-методик яктан тәэмин итү;

2) закон һәм башка норматив хокукый актларны тормышка ашыруны тәэмин итү;

3) муниципаль оешмаларның наркотизацияләүне профилактикалау системасы эшчәнлеген координацияләү;

4) шәһәр халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау формаларын һәм методларын камилләштерү;

5) наркоманияне профилактикалауга һәм сәламәт яшәү рәвеше стандартларын формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру;

6) наркотикларга каршы көрәштә массакүләм мәгълүмат чараларыннан, иҗтимагый һәм дини оешмалардан файдалану;

Программаны тормышка ашыру механизмы – шәһәр халкы тарафыннан наркотик һәм психоактив матдәләр куллануны киметүне тәэмин итүче чараларны эзлекле рәвештә гамәлгә ашыру.

Тормышка ашыру механизмы түбәндәгеләрне күздә тота:

1) наркоманияне профилактикалау өлкәсендә бер тапкыр үткәрелә торган чаралардан озак сроклы проектларга күчүне тәэмин итү;

2) наркотизацияләүне беренчел профилактикалау һәм савыгып килүче наркотикка бәйлеләрне социаль адаптацияләү өлкәсендә эшләүче муниципаль структуралар, яшьләр иҗтимагый оешмалары эшчәнлеген активлаштыру аша наркомания, иртә алкоголизм һәм тәмәке тарту проблемасын хәл итүгә комплекслы якын килүне тәэмин итү;

3) җирле үзидарә органнары, коммерцияле булмаган оешмалар арасында наркоманияне профилактикалау һәм наркотикка бәйлеләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү;

4) төрле максатчан төркемнәр арасында куркынычсыз яшәү күнекмәләрен үстерү принципларына нигезләнгән профилактика программаларын кертү;

5) яшьләрнең аеруча тиз бирешүчән вәкилләре өчен муниципаль хезмәтләр сыйфатын күтәрү;

6) региональара оешмалар белән партнерлык элемтәләрен җайга салуда ярдәм күрсәтү, наркотизацияләүне профилактикалау буенча социаль инициативалар өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу;

7) шәһәр оешмаларында наркоситуация мониторингын үткәрү һәм профилактик эш оештыру аша наркотикларга каршы максатчан эшнең уңышлы тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату, ирешелгән нәтиҗәләрне өзлексез анализлау механизмын эшләү һәм гамәлгә кертү;

8) наркотик чараларны күп куллануга каршы тору проблемалары буенча хокукый базаны формалаштыру һәм яңарту;

9) педагогик кадрларны һәм яшьләр белән эшләүче белгечләрне, профилактика технологияләренә һәм наркотик матдәләр куллланучы затларны иртә ачыклау методларына өйрәтү.

Программа чараларын тормышка ашыру өчен башкаручылар, эшләрнең составы һәм эзлеклелеге, башкару сроклары һәм җаваплы затлар, шулай ук эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү буенча контроль чаралар (программага 1 нче, 2 нче кушымталар) билгеләнгән.

Яр Чаллы шәһәрендә наркотикларга каршы профилактик эшне координацияләүне наркотикларга каршы комиссия гамәлгә ашыра. Ел саен кварталга бер тапкыр комиссия утырышлары уза, аларда шәһәрдә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау проблемалары буенча мәсьәләләр карала.

Каралган мәсьәләләр буенча тиешле карарлар кабул ителә һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту алып барыла.

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга программаны финанслау күләме 1200 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет акчалары:

Чор өчен барлыгы 1200 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2023 ел – 400 мең сум, 2024 ел – 400 мең сум, 2025 ел – 400 мең сум.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган индикаторлар:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Яшьләр сәясәте, өстәмә белем бирү, мәдәният һәм спорт учреждениеләрендә мәшгуль 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләр өлеше, әлеге яшь төркеменең гомуми санынннан | $C=\frac{C1x100\%}{C2}$<br><br>монда С1 – яшьләр сәясәте, өстәмә белем бирү, мәдәният һәм спорт учреждениеләрендә мәшгуль яшьләр саны;<br><br>С2 – яшьләрнең гомуми саны (агымдагы елга статистик мәгълүматлар буенча) | Күрсәтелгән максатчан төркемнең мәшгуль яшьләре саны турында идарәләрнең статистик хисаплары<br><br>Яр Чаллы шәһәре статистика бүлегенең статистик мәгълүматлары |
| 2. | Профилактик чараларда катнашкан яшүсмерләр һәм яшьләр өлеше | $C=\frac{C1x100\%}{C2}$<br><br>монда С1 – профилактик чараларда катнашкан яшьләр саны;<br><br>С2 – яшьләрнең гомуми саны (агымдагы елга статистик мәгълүматлар буенча) | Күрсәтелгән максатчан төркем өчен үткәрелгән профилактик чаралар турында идарәләрнең аналитик хисаплары,<br><br>Яр Чаллы шәһәре статистика бүлегенең статистик мәгълүматлары |

## 7 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре көтелгән ахыргы нәтиҗәләргә ирешү буенча бәяләнә:

1) наркотик матдәләр кулланучы затлар саны арту динамикасын киметү;

2) дәвалау-реабилитация ярдәме өчен, наркотик матдәләргә бәйле затларның Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика наркология

диспансеры» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесенең филиалы – «Яр Чаллы наркология диспансеры»на мөрәҗәгать итүен арттыру;

3) наркотик матдәләрне күп кулланучы затларга медицина-социаль-реабилитация ярдәме күрсәтү нәтиҗәлелеген арттыру;

4) наркотизацияләү проблемасы һәм беренче пробаларны кисәтү чаралары буенча халыкның төрле төркемнәренең мәгълүмат кырын киңәйтү.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасына
1 нче кушымта

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2022 ел база | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2023 ел мең сум | 2024 ел мең сум | 2025 ел мең сум |
| Программаның максаты: Сәламәт яшәү стилен формалаштыруга юнәлдерелгән комплекслы чаралар системасын, Яр Чаллы шәһәре халкы арасында психоактив матдәләр куллану һәм таратуга комачаулаучы үз-үзеңне тоту стратегияләрен һәм шәхес ресурсларын булдыру | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| Яшьләр сәясәте, өстәмә белем бирү, мәдәният һәм спорт учреждениеләрендә мәшгуль 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләр өлеше, әлеге яшь төркеменең гомуми саныннан, % | | | | - | 76,5 | 77,5 | 78,5 | 79,5 | - | - | - |
| Профилактик чараларда катнашкан яшүсмерләр һәм яшьләр өлеше, % | | | | - | 76,5 | 77 | 77,5 | 78 | - | - | - |
| 1 бурыч. Халыкта наркотиклар куллануга тискәре караш һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру, халыкның төрле максатчан төркемнәре өчен наркотикларга каршы профилактик чаралар оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | | |
| 1. | «Шәхси стратегияләр коучы» проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Үткәрелгән һәм оештырылган чаралар саны, берәмлек | 10 | 15 | 15 | 15 | 30 | 30 | 30 |
| | | | | Чараларда катнашкан яшьләр саны, кеше | 200 | 350 | 350 | 350 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | «#АчыкДиалог» мәгълүмат мәйданчыгын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Үткәрелгән мәгълүмат-агарту чараларының саны, берәмлек | - | 5 | 5 | 5 | 40 | 40 | 40 |
| | | | | Чараларга җәлеп ителгән яшьләр саны, кеше | - | 300 | 300 | 300 | | | |
| 3. | «#СКРИН» наркотикларга каршы платформа» яшьләр активлыгы проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Проект кысаларында үткәрелгән профилактик чаралар саны, берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 | 50 | 50 | 50 |
| | | | | Конкурс чараларында катнашкан яшьләр саны, кеше | 100 | 200 | 200 | 200 | | | |
| 4. | «YOUность» (Юность) профилактика проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 10 | 15 | 15 | 15 | 30 | 30 | 30 |
| | | | | Чараларда катнашкан яшьләр саны, кеше | 100 | 350 | 350 | 350 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Яр Чаллы шәһәренең балалар һәм яшьләр берләшмәләре арасында «СпАРТиан уеннары» турниры» спорт-профилактика проекты үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән уеннар саны, берәмлек | 5 | 5 | 5 | 5 | 30 | 30 | 30 |
| | | | | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | 300 | 300 | 300 | 300 | | | |
| 6. | Наркотикларга каршы «Dance & health» («Бию һәм сәламәтлек») проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Шатлык» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | - | 120 | 120 | 120 | 30 | 30 | 30 |
| | | | | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 5 | 5 | 5 | 5 | | | |
| 7. | «Яр Чаллы шәһәренең эшләүче яшьләр шәһәр спартакиадасы» спорт-профилактика проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Заман» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Катнашкан оешмалар саны, берәмлек | 30 | 30 | 30 | 30 | 20 | 20 | 20 |
| | | | | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | | | |
| 8. | «Класс команда» психологик-педагогик проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Заман» ЯҮ МАУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 13 | 13 | 13 | 20 | 20 | 20 |
| | | | | Проектта катнашкан яшүсмерләр һәм яшьләр саны, кеше | - | 300 | 300 | 300 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Наркотикларга каршы «Киләчәккә юл» велоквесты үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 1 | 1 | 1 | 20 | 20 | 20 |
| | | | | Проектта катнашкан яшүсмерләр һәм яшьләр саны, кеше | - | 100 | 100 | 100 | | | |
| 10. | Яшүсмерләр һәм яшьләр өчен наркотикларга каршы «Мин сайлыйм!» шәһәр фоумы үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 12 | 12 | 12 | 30 | 30 | 30 |
| | | | | Форумда катнашкан яшүсмерләр һәм яшьләр саны, кеше | - | 300 | 300 | 300 | | | |
| 12. | «Сәламәт принцип» профилактик чаралар комплексын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Нур» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | 25 | 25 | 25 |
| | | | | Чараларда катнашкан яшьләр саны, кеше | 90 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 13. | «Синең Территория» шәһәр яшьләр профилактика проекты үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Нур» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 | 25 | 25 | 25 |
| | | | | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 бурыч. Шәһәр халкы арасында наркоманияне профилактикалауга мәгълүмат-пропаганда ярдәме күрсәтүне тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| 1. | «СФЕРА» мәгълүмат-медиа киңлеге» проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Мәгълүмати материаллар саны, берәмлек | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 50 | 50 | 50 |
| Барлыгы: | | | | | | | | | 400 | 400 | 400 |

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә
халыкны наркотизацияләүне профилактикалау»
муниципаль программасына
2 нче кушымта

Программа чаралары

| Т/с | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Программа чараларын башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Программаны тормышка ашыруны оештыру-методик тәэмин итү | | | | |
| 1. | Наркотикка бәйлелек проблемалары һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча ата-аналар өчен мәгълүмати-агарту чаралары үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | Гаилә мөнәсәбәтләренең нәтиҗәле модельләре белән бәйле проблемалар буенча ата-аналарның белемнәрен арттыру, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерү |
| 2. | Яшьләр сәясәте оешмаларында профилактик эшләрне оештыру буенча яшьләр белән эшләүче белгечләр өчен укыту семинарлары үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Яшьләр мохитендә наркоманияне профилактикалау буенча фәнни-нигезле программалар, заманча эш формалары һәм методлары кертү |
| 3. | «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе базасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча махсуслаштырылган әдәбият фондын формалаштыруны дәвам итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Мәдәният учреждениеләрендә методика базасы булдыру, наркотизацияләүне профилактикалауга яңа технологияләр кертү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Барлык типтагы белем бирү оешмаларында укучылар өчен әхлак һәм сәламәтлек буенча кинолекторийларны, киноәңгәмәләрне үз эченә алган наркомания проблемалары буенча кинолар күрсәтү (шул исәптән психологларны, табиб-наркологларны һ.б. чакырып) | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | Яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә наркотик матдәләр кулланугa карата тискәре караш тәрбияләү |
| 5. | Профилактика системасы белгечләре катнашында наркотизацияләүне профилактикалау проблемалары буенча конференцияләр, конкурслар, түгәрәк өстәлләр оештыру һәм үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Наркоманияне профилактикалауның заманча технологияләрен һәм ысулларын өйрәнү һәм тарату, тәҗрибә алмашу, халыкның дифференциацияләнгән төркемнәре арасында профилактик эш оештыруда нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү |
| 6. | Бәйлелек проблемалары буенча «Яшьләр ышаныч телефоны» балалар һәм яшьләр өчен телефон аша ашыгыч психологик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең телефон линиясенә мөрәҗәгатьләрне мониторинглау | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Телефон мөрәҗәгате буенча халыкка махсуслаштырылган ашыгыч ярдәм күрсәтү. Наркотикка бәйлеләргә ярдәм күрсәтүче хезмәтләр турында халыкка мәгълүмат бирү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. Закон һәм башка норматив хокукый актларны тормышка ашыруны тәэмин итү | | | | |
| 7. | «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирә тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке куллану нәтиҗәләреннән саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән:<br>- тәмәке тартуның зыяны турында белемнәрне массакүләм мәгълүмат чараларында даими рәвештә пропагандалау;<br>- белем бирү программаларына тәмәке тартуның кеше организмына йогынтысын өйрәнүгә кагылышлы бүлекләрне кертү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Әйләнә-тирәдә тәмәке төтене йогынтысын булдырмауга һәм яшьләр арасында тәмәке куллануны киметүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру |
| 8. | Яшүсмерләр һәм яшьләр тарафыннан төрле төрдәге психоактив матдәләр куллану проблемалары буенча белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре, педагог-психологлары өчен мәгълүмати-методик семинар-практикумнар уздыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Белем бирү оешмаларында психоактив матдәләр куллануны профилактикалау буенча яшүсмерләр белән эшләү күнекмәләренә өйрәтү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | «Студент яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тәртибен профилактикалау буенча шәһәрнең югары һәм һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында психологик хезмәтләр эшен оештыру» ведомствоара хезмәттәшлек программасын тормышка ашыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Шәһәрнең югары һәм һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында студент яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тәртибен профилактикалау буенча психологик хезмәтләр эшчәнлеген оештыруда бердәм принципиаль алымнар үтәлешен тәэмин итү |
| 10. | «Балигъ булмаганнарның асоциаль һәм деструктив тәртибен профилактикалау» гомуми белем бирү учреждениеләре педагог-психологлары белән ведомствоара хезмәттәшлек программасын тормышка ашыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Асоциаль һәм деструктив тәртипне профилактикалау буенча балигъ булмаганнар белән эшләүне оештыру мәсьәләләре, формалары һм методлары буенча гомуми белем бирү оешмаларының педагог-психологлары эшчәнлеген методик, мәгълүмати тәэмин итү һәм камилләштерү |
| 3. Шәһәр халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау формаларын һәм методларын камилләштерү | | | | |
| 11. | Яшьләрне һәм балигъ булмаганнарны иҗади берләшмәләргә, спорт секцияләренә, хезмәт эшчәнлегенә, социаль әһәмияткә ия эшчәнлеккә җәлеп итүне тәэмин итү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең мәшгульлеген һәм буш вакытларын тәэмин итү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12. | Шәһәр халкы өчен массакүләм спорт чаралары оештыру һәм үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, шәһәрнең физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халкы санын арттыру |
| 13. | Түбәндәгеләр арасында Спартакиада үткәрү:<br>- шәһәр студентлары;<br>- балалар һәм яшүсмерләр клублары;<br>- иҗтимагый оешмалар | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Балаларны һәм яшьләрне физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру |
| 14. | Яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча «Минем дөньям» программасын тормышка ашыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, яшьләргә психоактив матдәләр куллану нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү |
| 15. | Мәгариф, спорт, мәдәният һәм яшьләр сәясәте учреждениеләрендә, шулай ук социаль челтәрләрдә һәм оешмалар сайтында наркотикларга каршы мәгълүмат урнаштыруны оештыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Җәмгыятьтә психоактив матдәләрне медицина максатыннан тыш куллануга тискәре мөнәсәбәт формалаштыру. Наркотик матдәләрнең законсыз әйләнешендә катнашкан өчен тискәре нәтиҗәләр һәм җаваплылык турында хәбәрдарлык дәрәҗәсен күтәрү |

| 4. Наркоманияне профилактикалауга һәм сәламәт яшәү рәвеше стандартларын формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 16. | Наркотикларга каршы профилактика проектларын һәм программаларын, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, позитив тормыш кыйммәтләрен пропагандалау программаларын тормышка ашыру буенча муниципаль, республика конкурсларында катнашу | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | Яшүсмерләр-яшьләр мохитендә профилактик чараларны тормышка ашыру өчен грант чараларын җәлеп итү |
| 17. | Гомуми белем бирү оешмаларында шәһәрнең һөнәри һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга (студентларга) социаль-психологик тест уздыру. «Куркыныч төркем» яшьләре белән эш оештыру | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | «Куркыныч төркем» укучылары һәм аларның ата-аналары белән индивидуаль һәм төркемле психологик-педагогик эш оештыру |
| 18. | Наркотикларга каршы профилактика программаларын тормышка ашыру; гомуми белем бирү оешмаларында, шәһәрнең һөнәри һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында, яшьләр сәясәте өлкәсе оешмаларында яшүсмерләр һәм яшьләр өчен профилактик чаралар үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру, яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә шәхси ресурсларны һәм компетенцияләрне үстерү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19. | Гомуми белем бирү оешмаларында, шәһәрнең һөнәри һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында, яшьләр сәясәте өлкәсе оешмаларында наркотикларга каршы профилактик эш оештыруның нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | Профилактик эшне оештыру буенча материалларга һәм документларга эксперт бәяләмәсен гамәлгә ашыру. Яшьләр сәясәте өлкәсендәге оешмалар, белем бирү оешмалары эшчәнлеген анализлау, профилактик эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр эшләү |
| 20. | Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны наркотикларның законсыз әйләнешенә җәлеп итүне профилактикалау буенча чаралар оештыру һәм үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Шәһәрнең гомуми белем бирү оешмалары укучыларының җинаятьчел тәртибен кисәтү |
| 21. | «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы» террорчылыкка каршы акциясе үткәрү | Финанслау каралмаган, чара оештыру характерына ия | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, яшьләргә психоактив матдәләр куллану нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү. Профилактик чараларны тормышка ашыру. |